| | |
|---|---|
| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «МИЧУРИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МИЧУРИН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» **МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 4 октябре № 21

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2021 елның 28 июнендәге 228-ФЗ номерлыФедераль закон нигезендә, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.17 статьясының 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 1 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

9 статьяның 9 пунктындагы 3 абзацын «,бюджетның бердәм счетында калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

34 статьяның 27 пунктына түбәндәге эчтәлектәге тәкъдим белән тулыландырырга: «Кредит (заем, облигациядән тыш) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүче муниципаль гарантия кредит килешүендә (займ килешүендә) һәм (яки) шартнамәдә күрсәтелгән муниципаль гарантияне бирү турындагы шартнамәдә кредитор (заемчы) йөкләмәләрен үз якларыннан күрсәтелгән кредит (займ) акчаларын максатчан файдалануны тикшереп торуны гамәлгә ашыру шарты белән бирелә.»;

36 статьяның 5 өлешен түбәндәге эчтәлекле яңа 2.1 пункт белән тулыландырырга:

«2.1) Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча ачык хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документларда;».

(2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә)

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин авылы, Совет ур., 26 – административ бина, Совет ур., 28 - мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк урамы, 9 - мәдәният йорты бинасы, Үзәк урамы, 15 - мәктәп

бинасы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

«Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.А.Иванова